ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 19 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасы булып кече һәм урта эшкуарлык субъектларын булдыру өчен шартлар тәэмин итә торган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларны), муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) гамәлгә ашырганда дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру һәм аларга ярдәм итү өчен тәэмин итүчеләр (башкаручылар, подрядчылар) сыйфатында булдырыла, үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра яисә җәлеп ителә торган коммерция оешмалары һәм коммерциягә карамаган оешмалар системасы тора.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасына шулай ук түбәндәгеләр керә:

1) эшкуарлыкны үстерү үзәкләре һәм агентлыклары;

2) эшкуарлыкка ярдәм итүче дәүләт фондлары һәм муниципаль фондлар;

3) кредитлаштыруга булышу фондлары (гарантия фондлары, поручительлек фондлары);

4) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен инвестицияләр җәлеп итү фондлары;

5) технопарклар һәм технопарклар белән идарә итүче оешмалар;

6) инновация-технология үзәкләре;

7) бизнес-парклар һәм бизнес-парклар белән идарә итүче оешмалар;

8) бизнес-инкубаторлар;

9) һөнәрләр палаталары һәм үзәкләре;

10) субподрядка ярдәм итү үзәкләре,

11) маркетинг һәм уку-эш үзәкләре;

12) экспортка ярдәм итү үзәкләре,

13) лизинг компанияләре;

14) консультация үзәкләре;

15) индустрия (сәнәгать) парклары һәм индустрия (сәнәгать) парклары белән идарә итүче компанияләр;

16) сәнәгать технопарклары һәм сәнәгать технопарклары белән идарә итүче компанияләр;

17) технологияләрне коммерциальләштерү үзәкләре;

18) югары технологияле җайланмалардан күмәк файдалану үзәкләре;

19) инжиниринг үзәкләре;

20) прототиплаштыру һәм сәнәгать дизайны үзәкләре;

21) технологияләрне трансферлау үзәкләре;

22) кластер үсеше үзәкләре;

23) эшчәнлекләрен Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыра торган фәнни, фәнни-техник эшчәнлеккә, инновация эшчәнлегенә ярдәм итүче дәүләт фондлары;

24) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм (яисә) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга микрозаемнар бирүче микрофинанс оешмалары;

25) социаль өлкә инновацияләре үзәкләре;

26) сертификацияләү, стандартлаштыру һәм сынау үзәкләре;

27) халык сәнгать кәсепләренә ярдәм итү үзәкләре;

28) авыл һәм экология туризмын үстерү үзәкләре;

29) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына хезмәт күрсәтүче дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре;

30) сәүдә-сәнәгать палаталары;

31) авыл хуҗалыгы кооперациясе һәм фермерларга ярдәм итү өлкәсендә компетенцияләр үзәкләре;

32) финанс агентлыклары;

33) кооперативлар;

34) хокук үзәкләре;

35) махсуслаштырылган җитештерү территорияләре (җитештерү-технология зоналары);

36) бизнес-кунакханәләр;

37) фәнни-тикшеренү оешмалары;

38) технополислар белән идарә итүче оешмалар;

39) фәнни парклар һәм фәнни парклар белән идарә итүче оешмалар;

40) агросәнәгать парклары һәм агросәнәгать парклары белән идарә итүче оешмалар;

41) бүтән оешмалар.»;

2) 18 статьяның 5 пунктында «технопарклар,» сүзеннән соң «бизнес-парклар,» сүзен өстәргә;

3) 21 статьяга түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$) авыл хуҗалыгы кооперациясе һәм фермерларга ярдәм итү өлкәсендә компетенцияләр үзәкләрен булдыру һәм мондый үзәкләр эшчәнлеген тәэмин итү;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 02 ноябрь
№ 102-ТРЗ